ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1.02.2022 г.Лениногорск № 76

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 16 декабрендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номелы Федераль законның 39 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 16 декабрендәге 69 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге;

2) төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләрен һәм аның максатчан әһәмиятен, өстәлеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов

Лениногорск шәһәр Советының 2022 елның 1 февралендә кабул ителгән 76 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

| **Ииндикаторның исеме** | **Сайланган параметрның нормаль торышы (бәяләү критерийлары), үлчәү берәмлеге (булганда)** | **Риск индикаторы күрсәткече** |
|---|---|---|
| 1 индикатор исеме | 5-10, данә | < 5 данә яисә<br>> 10 данә |
| 2 индикатор исеме | юк | әйе |
| 3 индикатор исеме | 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә | Нормаль параметрларны 10% тан артыгракка киметү яки арттыру |

Вазифаның исеме ФИА.и

Лениногорск шәһәр Советының 2022 елның 1 февралендә кабул ителгән 76 номерлы карары белән расланды

**Тикшерү төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр**

1. Төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан әһәмияте:

Мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозулар арасыннан юк ителгән бозулар өлеше - 70%.

Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү өлеше - 100%.

Тикшерү органы һәм (яки) аның вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр өлеше - 0%.

Контроль чараларның юкка чыгарылган нәтиҗәләре өлеше - 0%.

Нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган, әмма тиешле административ йогынты ясау чаралары кабул ителмәгән контроль чаралар өлеше - 5%.

Тикшерү органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары өлеше - 95%.

2. Индикатив күрсәткечләр:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә:

үткәрелгән планлы контроль чаралар саны;

планнан тыш үткәрелгән контроль чаралар саны;

контроль чара актына карата кергән мөрәҗәгатьләр саны;

мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү саны.